ISPEC International Journal of Social Sciences & Humanities

E-ISSN: 2717-7262

Vol: 3, Issue: 1, 2019

# ФАТИХ КӘРИМНЕҢ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТӨП МОТИВЛАР

**Айгөл Фирдинат кызы Ганиева**

*филология фәннәре кандидаты*

**Ләйсән Рәдиф кызы Надыршина**

**Фатыйма Хәлиулла кызы Миңнуллина**

*филология фәннәре кандидаты*

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Leysan_tatar@mail.ru

**Аннотация**

Мәкалә Ф.Кәримнең Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән шигырь һәм поэмаларындагы төп мотивларны анализлауга багышлана. Бөек Ватан сугышы чорындагы иҗатында Ф.Кәрим иле, Ватаны өчен көрәшкән совет солдаты образын сурәтләү объекты итә һәм аны кансыз дошманга каршы куеп тасвирлый. Әсәрләрдә төп мотив буларак, иң беренче чиратта, көрәш яңгырый. Сугыш чоры концепциясенә тугры калып, Фатих Кәрим үлем – үлемсезлек категорияләре турында уйлана һәм тугын илең, халкың өчен көрәшеп үлү – мәңгелек яшәешкә ирешү ул дигән идеяне үткәрә.Сугыш кырларында да Фатих Кәрим, иң беренче чиратта, шагыйрь булып кала. Аның шигырьләрендә, шуңа бәйле рәвештә, җыр, иҗат мотивы килеп керә. Фатих Кәрим сугыш кырларында туган ягы турында гел уйлана. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә, шигырьләрнең аерым берләрендә төп структур берәмлек буларак кайту мотивы чыгыш ясый. Фатих Кәрим иҗатында җиңү мотивы да үзәк мотивларның берсенә әверелә. Поэмаларында исә автор көрәш, илгә тугрылык мотивларын аерым образларның шәхси фаҗигаләре аркылы җиткерә һәм аны илең өчен корбан булу мотивы белән бәйли.

**Төп сүзләр:** Фатих Кәрим, поэзия, Бөек Ватан сугышы, мотив, шигырь, поэма.

**ISPEC International Journal of Social Sciences & Humanities**
**E-ISSN: 2717-7262**
**Vol: 3, Issue: 1, 2019**

## THE MAIN MOTIVES IN FATIKH KARIM'S POETRY OF THE WAR YEARS

**Abstract**

The article is devoted to the analysis of the main motifs in the poems and poems of F. Karim created during the Great Patriotic War. In his work during the Great Patriotic War, the country of F. Karim was the object of depicting the image of a Soviet soldier fighting for his homeland and portraying it against a bloodless enemy. As the main motive in the works, first and foremost, the struggle resonates. Adhering to the concept of wartime, Fatih Karim contemplates the categories of death and immortality and carries out the idea that dying to fight for his native country and people is the attainment of eternal life. In his poems, therefore, the motive of song and creativity comes into play. Fatih Karim is always thinking about his homeland on the battlefields. In this regard, in some of the verses, the motive of returning as the main structural unit is expressed. The motive of victory in the works of Fatih Karim also becomes one of the central motives. In his poems, however, the author conveys the motives of struggle and devotion to the country through the personal tragedies of individual images and relates it to the motive of sacrifice for your country.

**Keywords:** Fatih Karim, poetry, Great Patriotic War, motive, poem, poem.

### Кереш

Үзенең күпсанлы каләмдәшләре кебек үк, Фатих Кәрим дә Бөек Ватан сугышында шагыйрь булып кына түгел, солдат булып та катнаша. 1941 елның ахырыннан алып 1945 елның 19 февраленә, батырларча һәлак булуына кадәр, Ф.Кәрим Мәскәүдән алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сузылган солдат юлын уза һәм шушы көрәш юлын үз поэзиясендә соклангыч шигъри көч белән гәүдәләндерә [Рәмиев, 2004: 5].

Фатих Кәрим Бөек Ватан сугышында катнашуын намус эше, дан эше дип саный. “Киләсе җиребезгә килеп җитеп, эшкә башладык. Хәзер инде кулга корал тотып Туган ил өчен көрәшәбез. Эш күп, вакыт юк. Тәүлекләр буе аякта торырга туры килә. Болар бар да дан эше” – дип яза ул фронттан җибәргән беренче хатында. Икенче бер хатында Ф.Кәрим фашизмга каршы корал белән дә, җыр белән дә көрәшүе турында әйтә: “Бөтен көчемне фашизмга каршы көрәшкә юнәлдерәм. Миллионлаган кызылармеецлар белән бергә, бер сафта Бөек Ватанымның, синең,

сөйгән балаларымның бәхетен даулыйм. Җырларымның ялкыннарын да ун тапкыр көчәйтеп, илем өстенә җиңү шатлыгы чәчәкләрен сибү көненә ышанычлы адымнар ясыйм...” [Рәмиев, 2004: 5]. Әлеге омтылыш, ялкынлы хис Ф.Кәримнең сугыш чоры лирикасында да үзәк урынны алып тора.

### Фатих Кәримнең бөек ватан сугышы чоры шигъриятендә төп мотивлар

Бу чорда шагыйрь иҗатының сурәтләү объекты үзгәрә. Әлеге шигырьләрдә сурәтләнгән герой – утлар-сулар кичеп чыккан совет солдаты, Ватан язмышы өчен соңгы тамчы канын да кызганмаган, “Үзең турында уйлама, илең турында уйла” (Ф.Кәрим) дип йөрткән каһарман. Биредә инде ул автор образы белән тәңгәллеген югалта, миллионлаган кеше, халык омтылышларын чагылдыра. Аның йөрәге туган халкына һәм иленә, кешелек мәдәниятенә, яктылыкка, тормышка мәхәббәт хисләре белән тулы. Ф.Кәримнең лирик герое коллыкны, караңгылыкны, фашизмны дошман күрә.

“Ватаным өчен” (1942) шигырендә сугыш чоры идеологиясе шундый хисләргә уралып бирелә, көрәш мотивы үзәк урынга чыга. Лирик герой үзенең дәһшәтле сугышка керәсен белә, сөйгәненә язган хатының соңгы булырга мөмкинлеген дә аңлый:

*Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,*

*Иң дәһшәтле утка керәмен,*

*Шулай була калса, кояшны да*

*Бүген соңгы тапкыр күрәмен*[Кәрим, 1989: 12].

Бу шигырьдәге хат образы – татар әдәбияты өчен традицион предмет образы. Биредә хат совет солдаты сурәтен алган лирик геройның сөйгәне белән саубуллашуы да, шул ук вакытта, аның яшәеш идеалларын җиткерүе дә.

Сугыш чоры концепциясенә тугры калып, Фатих Кәрим үлем – үлемсезлек категорияләре турында уйлана һәм туган илең, халкың өчен көрәшеп үлү – мәңгелек яшәешкә ирешү ул дигән идеяне үткәрә:

*Үләм икән, үкенечле түгел*

*Бу үлемнең миңа килүе,*

*Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен*

*Сугыш кырларында үлүе*[Кәрим, 1989: 12].

Димәк, бу әсәрдә яшәү – үлем антонимиясе сугыш таләп иткән рухта хәл ителә, төшенчәләрнең тәңгәл килүе күзәтелә. Әлеге ноктада ул М.Җәлил тәкъдим иткән идеология белән кисешә, шагыйрьнең “Моабит дәфтәрләре”ндәге бер бәйләм шигырьләргә аваздаш яңгырый.

“Дусларга” шигырендә (1942) сугыш китергән сагыш һәм җиңүгә ышаныч хисләре үзара каршылыкта бирелә. Шигырьнең беренче өлешендә лирик геройның сугышка киткәндә, якыннары белән хушлашу сагышы кичерүе сурәтләнә:

*Мин вокзалда, ашыгып, соңгы тапкыр*

*Казан кипятогын агыздым,*

*Котелогым тулды...*

*Күңелем тулды,*

*Кайчан күрешербез тагын без?*

*Калды Казан, балаларым калды,*

*Калды иркәм, калды киң Идел...*

*Дуслар калды... Киттем...*

*Мин киткәндә,*

*Тын алгысыз салкын көн иде* [Кәрим, 1989: 7].

Күренгәнчә, бу өлештә сагыш хисе үзәк урынны алып тора. Әмма бу инде тоткынлык чорындагы сагышлану түгел, Фатих Кәримнең лирик герое горурлык катыш хәсрәт хисләре кичерә: бер яктан, ул, әлбәттә, аерылу газабын тоя, ә икенче яктан исә, туган илен якларга китүе, данлы юлны сайлавы аны беркадәр тынычландыра, аерылуны мәгънәле итә. Шигырьнең икенче өлешендә турыдан-туры сугыш вакыйгалары сурәтләнә:

*Сугыш сугыш инде, рәхимсезлек*

*Ия булып йөри күңелгә:*

*Шпал итеп тезеп фашист гәүдәләрен*

*Юл салабыз бөек җиңүгә.*

*Бу юлларны салып барган чакта,*

*Уйга төшермисең үлемне...*

*Исән булсам, җиңү шатлыгында*

*Мин котлармын тиздән илемне* [Кәрим, 1989: 7].

Бирedә сугыш манзаралары патриотик хисләр белән тулыландырыла. Лирик геройның үлем турында уйламавы, үлемнән курыкмавы ил идеологиясе дәрәҗәсендә кабул ителә, ягъни бу чорда илдә хакимлек иткән идеологияне кабатлый. Димәк, киләсе көнгә ышаныч лирик геройның сагышлы хисләреннән юаныч булып тора. Фашист образының җиңелгән планда тәкъдим ителүе киләчәккә өметны арттыра.

Сугыш кырларында да Ф.Кәрим, иң беренче чиратта, шагыйрь булып кала. Ул, алда әйтелгәнчә, дошманга каршы көрәштә иҗатын да корал итә. Аның шигырьләрендә, шуңа бәйле рәвештә, җыр, иҗат мотивы килеп керә. “Кереш җыр” әсәрендә (1942) әлеге мотивлар үлемсезлеккә ирешүнең бер өлеше буларак карала:

*Ут булмаган җирдә ай яктырта,*

*Җыр хакына кала йокылар;*

*Окопларда язган җырларымны*

*Хөрмәт белән дуслар укырлар* [Кәрим, 1989: 11].

Шигырьнең нигезенә салынган төп идея түбәндәгечә яңгырый: лирик герой үлем куркынычы астында көрәшә, әмма аның киләчәккә өмете зур, үлемсезлеккә ирешү чарасы булган җырлары аның турында хәтерне саклар.

Ф.Кәрим сугыш кырларында туган ягы турында гел уйлана. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә, кайбер шигырьләрендә төп структур берәмлек буларак кайту мотивы яңгырый. “Юл” (1942) исеме белән аталган әсәрендә кайтуның булмаска да мөмкинлеге турында сүз алып барыла. Әмма кайтуның шарты бер: дошманны җиңәргә кирәк:

*Кайту да юк ләкин, кавышу да,*

*Дошманнарны әгәр җиңмәсәк,*

*Данлы җиңү байраклары белән*

*Илнең кайгы яшен сөртмәсәк* [Кәрим, 1989: 14].

Димәк, бу шигырьдә дошман – фашист образын җиңү мотивы киләчәккә баруның бердәнбер шарты итеп билгеләнә. Байрак образы, беренче чордагы идеологик мәгънәсен җуеп, халыкны бергә туплап торучы, җиңүне символлаштыручы образга әверелә.

Ф.Кәримнең бу чорда иҗат иткән әсәрләрендә поэма жанры үсешенә өлеш керткәннәре дә бар. Алар психологик тирәнлек белән аерым кеше язмышы аркылы сугыш ачысын сурәтләп бирүләре белән үзенчәлекле. Мәсәлән, әдипнең “Гөлсем” һәм “Партизан хатыны” поэмаларында хатын-кыз образлары үзәккә алына. “Гөлсем” әсәрендә баласы сызлануларына йөрәге әрнегән ананың хисләре фашистка олы нәфрәткә кадәр үстерелә. Хис-кичереш сызыгының бу рәвешле үсеше авторның психологик анализ осталыгына ирешүен күрсәтә. “Партизан хатыны” поэмасында да баласы, үзенең гомерен ил тынычлыгы өчен корбан иткән Ана образы калка:

*Кулымны кис, күзләремне чокы,*

*Башымны яр, мә, өз телемне,*

*Бер сүз көтмә. Мин иремне сатсам,*

*Бу бит сату Туган илемне* [Кәрим, 1989: 12].

“Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасында исә Фазыл образында батыр сугышчы идеалы калка.

Бөек Ватан сугышы халыкны бер йодрыкка туплый, җиңү хакына яшәтә. Фатих Кәрим иҗатында да җиңү мотивы үзәк мотивларның берсенә әверелә. Югарыда анализланган шигырь-поэмаларында да бу ачык күренде. Ә шагыйрьнең бик күпләр яттан сөйләгән “Сөйләр сүзләр бик күп алар” әсәрендә (1942) әлеге идея бөтен тулылыгы белән ачыла:

*Сөйләр сүзләр бик күп алар,*

*Иренмичә сөйләсәң;*

*Озын сүзнең кыскасы шул,*

*Күп яшәргә теләсәң:*

*Үлем турында уйлама,*

*Илең турында уйла,*

*Илең турында уйласаң,*

*Гомерең озын була* [Кәрим, 1989: 15].

Фатих Кәримнең яшәү шигаре дә нәкъ менә шушы шигырь юллары белән характерлана алыр иде. Бөек Ватан сугышы чорында иҗат иткән шигырьләрендә ул үзен чын патриот, көрәшче итеп таныта. Аның бу әсәрләрендә "бөек", "данлы", "дәһшәтле" эпитетлары кабатланып килә, шул ук вакытта шәхси лирик кичерешләргә дә зур урын бирелә. Әлеге шигырьләрдә хронотопның туган ил, җир кысаларыннан тагын үсеп, фашист юлбасарлары яуларга омтылган илләрне үз эченә алуы күзәтелә. Шагыйрьнең лирик герое инде үз кичерешләре белән генә яшәми, ул – совет солдаты булып уйлый, сугыш тудырган хакыйкатьне җиткерүчегә әверелә. Ә хакыйкать бер генә: илең өчен үлү – үлемсезлеккә ирешү чарасы. Әлеге идеяне җиткерүдә авторга ант, көрәш, җиңү, иҗат, җыр кебек мотивлар ярдәмгә килә.

**Йомгак**

Гомумән, Фатих Кәримнең поэзиясе катлаулы һәм киңкырлы. Иҗатының төрле чорларында ул ирек, бәхет, яшәү һәм үлем, яшәеш кебек мәңгелек төшенчәләр турында уйлана. Шуның белән дә аның иҗаты укучыны гел кызыксындыра һәм уйланырга мәҗбүр итә.

**Чыганаклар**

1.**КӘРИМ**, Фатих, (1989),*Илең турында уйла: Шигырьләр, поэмалар, балладалар*. Казан

2. **РӘМИЕВ,** Зөфәр, (2004),*Үлемсезлек // Кәрим Ф. Кыр казы: Шигырьләр, поэмалар*. Казан